| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

11 сентября 2024г. с.Шалты № 104

Шалты авыл җирлеге Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
19.12.2022 № 51 карарына үзгәрешләр
кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Шалты авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 19.12.2022 № 51 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2-нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 5-нче пунктча белән тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы күрсәтмәсе белән билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата 1,2 процент;»

5-нче пунктчаны 6-нчы пунктча дип санарга.

2. 2 пунктның 4 пунктчасындагы 2-3 абзацларының гамәлдә булуын 2028 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән алып 1 ай узганнан да иртәрәк түгел һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр белән гамәлдә була.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында bavly.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин